СОВЕТ КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.16, д.Пойкино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422142

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЛӘҮШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Октябрь ур., 16 нче йорт, Пойкино авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422142

тел.(факс): (85563) 3-89-193; e-mail: Kls.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

“02” октябрь, 2017 ел — № 1-25

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Келәүш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Келәүшавыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 че сентябрендә кабул ителгән 5 номерлы карары, Келәүш авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 че сентябрендә кабул ителгән 2-24 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүшавыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2017 нче елның 19 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру:

Пойкино торак пунктында, Келәүш торак пунктында, Тугыз торак пунктында Сарбаш торак пунктында, Гурьевка торак пунктында, Келәүш урманчылыгы торак пунктында су алу манарасын ремонтлау.

2. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

янгын гидранты җайланмасын сатып алу һәм урнаштыру:

Пойкино торак пунктында 2 шт.;

Келәүш торак пунктында 2 шт.;

Тугыз торак пунктында 1 шт.;

Келәүш урманчылыгы торак пунктында 1 шт.;

Сарбаш торак пунктында 1 шт.;

Гурьевка торак пунктында 1 шт.

«ДА» «НЕТ»

3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ивановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Келәүш авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Б.В.Иванов